КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 ноябрь г.Казань № 989

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 23 сентябрь, 910 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1363 нче; 2022 ел, 21 март, 251 нче; 2023 ел, 8 декабрь, 1579 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашырганда зыян (зарар) китерү рискының түбәндәге категорияләре (алга таба – риск категориясе) карала:

югары дәрәҗәдәге риск;

урта дәрәҗәдәге риск;

уртача дәрәҗәдәге риск;

түбән дәрәҗәдәге риск.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.7^{1}$ пункт өстәргә:

«$2.7^{1}$. Әгәр контрольдә тотылучы зат чираттагы календарь елга план буенча тикшерүләр үткәрү планын төзү датасына кадәр булган бер ел эчендә түбәндәгеләр өчен ике һәм аннан күбрәк тапкыр административ җаваплылыкка тартылса, хезмәткәрләр саны 1 000 һәм аннан күбрәк кеше тәшкил иткән контрольдә тотылучы зат эшчәнлеге югары дәрәҗәдәге риск категориясенә карый:

инвалидларны эшкә кабул итү өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын булдыру яки бүлеп бирү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән;

билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан баш тарткан.»;

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Контрольдә тотылучы затлар эшчәнлеген югары, урта һәм уртача риск категорияләренә кертергә мөмкинлек бирә торган хәлләр булмаганда, контрольдә тотучы затларның эшчәнлеге түбән дәрәҗәдәге риск категориясенә карый.»;

2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Бирелгән риск категориясеннән чыгып, контрольдә тотыла торган затларга карата план буенча документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр үткәрү түбәндәге вакыт аралыгында гамәлгә ашырыла:

югары дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – ике елга бер тапкыр;

урта дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – дүрт елга бер тапкыр;

уртача дәрәҗәдәге риск категориясе өчен – алты елга бер тапкыр.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин